# Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советы карары

Сарлы авылы                    № 86-44                    2018 ел, 30 март

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советының 2012 елның 19 апрелендәге 42 номерлы карары белән расланган Сарлы авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында (2015 елның 11 февралендәге129-75 номерлы, 2015 елның 11 сентябрендәге 149-84 номерлы, 2016 елның 10 мартындагы 25-11 номерлы карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 30 октябрендәге № 299-ФЗ, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 декабрендәге 455-ФЗ номерлы федераль законнарын үтәү өчен

Сарлы авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советының 2012 елның 19 апрелендәге 42 номерлы карары белән расланган Сарлы авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә (2015 елның 11 февралендәге 129-75 номерлы, 2015 елның 11 сентябрендәге 149-84 номерлы, 2016 елның 10 мартындагы 25-11 номерлы карарлар редакциясендә), 1.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, түбәндәге үзгәрешне кертергә:

«1.4. Халык тыңлауларына мәҗбүри тәртиптә чыгарыла:

1) җирлек уставы проекты, шулай ук гамәлдәге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт проекты, Уставка, гамәлдәге Уставны әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатларында, Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, конституция (Устав) яисә Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләрен төгәл кабатлау рәвешендә үзгәрешләр кертү очракларыннан тыш;

2) җирлек бюджеты проекты һәм аның үтәлеше турында хисап;

3) җирлекнең социаль-икътисадый үсеш стратегиясе проекты;

4) «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы нигезендә тавыш бирү юлы белән яисә гражданнар җыеннарында белдерелгән җирлек халкының ризалыгын алу таләп ителгән очраклардан тыш җирлекне үзгәртеп кору өчен.»

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://aznakayevo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Сарлы авыл җирлеге Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләнә.

Рәис М.Р.Шәрипов